Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Башкарма комитеты

# КАРАР

23 январь 2024 ел

№ 1

Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Әлмәт районында 2024 елның 18 гыйнварендагы 51-34-09/143 номерлы клиентлар хезмәте мөрәҗәгате (бүлек хокуклары) нигезендә

Яңа Нәдер авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 01 февраленнән Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталарга ярашлы рәвештә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында» 2023 елның 27 гыйнварендагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Нәдер авыл Башкарма
комитеты җитәкчесе

С.М. Миннебаев

Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Башкарма
комитетының
2024 елның «23» гыйнварендәге
1 номерлы карарына 1 нче
кушымта

Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләүләр өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 4 873,92 |
| 3 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Яңа Нәдер авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.М. Миннебаев

Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Башкарма
комитетының 2024 елның
«23» январендәге 1
номерлы карарына 2 нче
кушымта

Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләүләр өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гәүдәне төрү | 2 857,57 |
| 3 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 2 016,35 |
| 4 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Яңа Нәдер авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.М. Миннебаев